**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 27 февраль № 123

г. Казань

Татарстан Республикасында социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары найм шартнамәләре буенча торак урыннарны наемга алган өчен түләүнең максималь күләме, аны билгеләү, үзгәртү һәм ел саен индексацияләү тәртибе турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары найм шартнамәләре буенча торак урыннарны наемга алган өчен түләү билгеләү, үзгәртү һәм ел саен индексацияләү тәртибе турында» 2014 ел, 12 декабрь, 1356 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урынның 1 кв.метр гомуми мәйданына исәпләгәндә торак урыннарны наемга алган өчен түләүнең максималь күләмен (алга таба – торак урыннарны наемга алган өчен түләүнең максималь күләме) социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урынның 1 кв.метр гомуми мәйданына 33,68 сум күләмендә расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

торак урыннарны наемга алган өчен түләүнең максималь күләме наемга бирелгән торак урын урнашкан яки наемга бирелгән торак йорт булып торучы, социаль файдаланудагы наем йортын төзүгә йә социаль файдаланудагы мондый наем йортындагы барлык урыннарны яки мондый торак йортны сатып алуга торак урын милекчесе чыгымнарын каплауны кертеп, икътисадый нигезләнгән чыгымнардан һәм социаль файдаланудагы наем йортын капиталь ремонтлауга бәйле булган хезмәт күрсәтүләргә түләүдән чыгып билгеләнә дип;

торак урыннарны наемга алган өчен түләүнең максималь күләмен билгеләү өчен андагы торак урыннарны экономияле классны торакка кертүнең Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан билгеләнгән шартларына туры килә торган күпфатирлы йорт булып торучы социаль файдаланудагы бертип наем йорты тасвирламалары кабул ителә дип;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәрләре яктылыгында торак урыннарны наемга алган өчен түләүне дифференциацияләү, төзекләндерү дәрәҗәсенә бәйле рәвештә, социаль файдаланудагы наем йорты белән идарә итүгә, аны карап тотуга һәм аңа агымдагы ремонтны үткәрүгә бәйле булган хезмәт күрсәтүләргә фактта түләүне исәпкә алып гамәлгә ашырыла дип;

торак урыннарны наемга алган өчен түләүнең максималь күләмен яңадан карау иң күбе өч елга бер тапкыр гамәлгә ашырыла дип;

торак урыннарны наемга алган өчен түләүнең максималь күләме, Татарстан Республикасында куллану бәяләренең Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы билгели торган индексыннан чыгып, агымдагы елның 1 мартыннан да соңга калмыйча (узган календарь елына карата уртача хисап календарь елы өчен) ел саен индексацияләнә дип;

торак урыннарны наемга алган өчен түләүнең максималь күләмен үзгәртү турында агымдагы елда карар кабул ителгән очракта, торак урыннарны наемга алган өчен түләүнең максималь күләмен индексацияләү гамәлгә ашырылмый дип.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\123.doc